**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «25» маеннан № 127

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 229 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 1270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 21 ноябрендәге 979 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Педагогик хезмәткәрләргә - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының яшь белгечләренә айлык тимуллаштыручы өстәмә түләү билгеләү турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 229 номерлы карарына (2021 елның 14 маендагы 222 номерлы, 2021 елның 16 ноябрендәге 446 номерлы, 2023 елның 11 апрелендәге 108 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы спорт министрлыгы башкара торган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшләүче педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыру өстәмәләрен түләү турында түбәндәге карар белән расланган тәртиптә:

14 пунктта:

дүртенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

дүртенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «2510 сум» сүзләрен «10000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https:///pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Бутина Анна Ивановнага йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Исполнительный комитет Новошешминского муниципального района Республики Татарстан
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты
ИНН 1631003397
ОГРН 1051660041740